ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул.Школьная, д.17,

с.Акбаш, 423958

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ

РАЙОНЫ АКБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Мәктәп урамы, 17йорт,

Акбаш авылы, 423958

Тел.:(85593) 4-14-34, факс:4-14-34, e-mail: Akbash.Utz@tatar.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**КАРАР**

**№ 37** **29.11.2023 ел**

«Муниципаль контрактлар буенча товарлар, эшләр (хезмәт күрсәтүләр) кабул итү комиссиясе турындагы нигезләмәне раслау хакында һәм Татарстан Республикасы Ютазы районының Акбаш авыл җирлеге ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр, муниципаль контрактлар буенча хезмәт күрсәтүләр алу комиссиясе составын раслау турында»гы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

2003 елның 06 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль закон, 2010 елның 27 июлендәге «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында»гы 210-ФЗ санлы Федераль закон, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Акбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Акбаш авыл җирлеге башкарма комитеты

карар бирә:

1. «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Акбаш авыл җирлеге башкарма комитетының 2016 елның 15 февралендәге 3 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Акбаш авыл җирлеге ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр (хезмәт күрсәтүләр) кабул итү комиссиясе турында һәм муниципаль контрактлар буенча комиссия составын раслау хакында»гы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 1.3. абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3. Үз эшчәнлегендә кабул итү комиссиясе Россия Федерациясе Граждан кодексы, "Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында" Федераль закон, 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ санлы, башка норматив хокукый актлар, муниципаль контракт шартлары һәм әлеге

Нигезләмә белән җитәкчелек итә.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Акбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгару һәм Татарстан Республикасының Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасының Бердәм муниципаль берәмлекләре порталы составында «Рәсми Татарстан» дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм Порталы составында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә игълан ителгән көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Акбаш авыл җирлеге башлыгы
вазыйфаларын башкаручы Г.Ф.Хаҗиева